**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.07.2013 № 7-16/т

Казан ш.

***Чаллы шәһәрендә «Промжелдортранс-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдалануда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында***

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 07 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чаллы шәһәренең «Промжелдортранс-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдалануда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә, әлеге карар кушымтасына туры китереп, чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Чаллы шәһәре «Промжелдортранс-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдалануда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү турында» 2012 елның 25 маендагы 7-7/т номерлы карарының 1 пунктының көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
05.07.2013 № 7-16/т
карарына кушымта

# Чаллы шәһәренең «Промжелдортранс-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланууда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар

## 1 бүлек. Чик дәрәҗә максималь тарифлар

| № п/п | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗәдә максималь тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1 | Сидоров маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 7,85 |
| 2 | Автозавод маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 11,18 |
| 3 | Камаз маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 8,63 |

## 2 бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгый тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләргә I «Чик дәрәҗә максималь тарифлар» бүлегендә каралмаган тарифлар Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы боерыгы белән расланган Сәнәгый тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләргә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә якларның килешүендә билгеләнә.
2. Йөк ташу һәм төяп җибәрү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан ташылган йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.
3. Йөк ташу буенча түләү алу өчен ераклык төгәл санга түгәрәкләп, километрларда билгеләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге